Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы
Турай авыл җирлеге Советы

КАРАР

2023 елның 16 гыйнвары №73

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районының
Турай авыл җирлеге башлыгы
вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату
турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 36 статьясындагы 6 пункты нигезендә, «Менделеевск муниципаль районының Турай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә һәм Рәхимова А.М. шәхси гаризасы нигезендә,

Менделеевск муниципаль районының Турай авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Турай авыл җирлеге башлыгы вазыйфасыннан шәхси гаризасы нигезендә Рәхимова Альфира Минерафис кызының үз теләге белән китүен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Турай авыл җирлеге башлыгы Рәхимова Альфира Минерафис кызының вәкаләтләрен вакытыннан алда 2023 елның 16 гыйнварыннан туктатылган дип санарга.

3. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советы депутаты Рәхимова Альфира Минерафис кызының вәкаләтләрен вакытыннан алда туктатылган дип санарга.

Менделеевск муниципаль районы
Турай авыл җирлеге советы
рәисе урынбасары Р.Р. Шәймөхәммәтов